**Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы Ключи җирлеге составына керүче Ключи авылы торак пунктында гражданнар җыены карары**

2023 елның 21 ноябре № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 һәм 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына нигезләнеп, Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы Ключи авыл җирлегенең Ключи авылы торак пунктында гражданнар җыены

Карар кабул итте:

1. 2024 елда Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы Ключи авыл җирлегенең Ключи авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучыларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, мобилизацияләнгән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 500 сум күләмендә гражданнарның үзара салым салуын кертергә.
2. Җыелган акчаларны Ключи авылындагы чишмәне төзекләндерүгә юнәлтергә.

**Гражданнар җыенында рәислек итүче-**
**Ключи авыл җирлеге башлыгы А. А. Карпухин**